КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 9 сентябрь г.Казань № 851

«Казан – Болгар – Казан» һәм (яки) «Казан – Свияжск – Казан» муниципальара даими йөртүләр маршрутлары буенча автомобиль транспорты белән пассажирлар йөртүне һәм багажлар ташуны гамәлгә ашыручы юридик затлар, индивидуаль эшмәкәрләр алып бетермәгән керемнәрне каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «Казан – Болгар – Казан» һәм (яки) «Казан – Свияжск – Казан» муниципальара даими йөртүләр маршрутлары буенча автомобиль транспорты белән пассажирлар йөртүне һәм багажлар ташуны гамәлгә ашыручы юридик затлар, индивидуаль эшмәкәрләр алып бетермәгән керемнәрне каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан – борынгы Болгар шәһәре – Казан» һәм «Казан – Свияжск утрау- шәһәре – Казан» маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы автотранспорт предприятиеләре алып бетермәгән керемнәрне каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында » 2014 ел, 29 декабрь, 1057 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин